Республика Татарстан
Глава
Вахитовского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
башлыгы

ул.Центральная, д. 30, пос.Победа
Азнакаевский район, 423312

Үзәк урамы, 29 нче йорт, Җиңү
бистәсе, Азнакай районы, 423312

Тел. (факс) 8(85592) 42-1-38; e-mail: Vahit.Azn@tatar.ru
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«13» ноябрь 2020 ел. №2

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Жину торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Вахитовы авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында Үзәк урам 29 йорт адресы буенча урнашкан Җиңү бистәсе мәдәният йортында 2020 елнын 25 ноябрендә 10.00 сәгать минутта Җиңү торак пункты Үзәк урам 1 йорттан 37 йортка, Үзәк тыкрык урамы 1 йорттан 3 йортка, Кибет урамы 1 йорттан 12 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында 2021 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2 Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында Үзәк урам 29 йорт адресы буенча урнашкан Җиңү бистәсе мәдәният йортында 2020 елнын 25 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Җиңү бистәсе Яшел урам 3 йорттан 89 йортка, 4 йорттан 70 йортка, Яшьләр урамы 2 йорттан 9 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында 2021 елда гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында Үзәк урам 29 йорт адресы буенча урнашкан Җиңү бистәсе мәдәният йортында 2020 елның 15 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Җиңү бистәсе Татарстан урамы 1 йорттан 10 йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пунктында 2021 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны раcларга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Беек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Җиңү торак пунктында авыл урам Яшел урамы буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту (асфальт-бетон ослекле юлларның чокырларын ямау)

- Җиңү торак пунктында мөселман зиратында контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләр алу өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез, киртәләр урнаштыру);

- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен чапкыч, трактор өчен отвал сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Җиңү торак пунктында җирлекне яктырту һәм буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү);

- Җиңү торак пунктында "Җиңү кене", "Сабантуй", "Халыкара өлкәннәр көне", «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;

« РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6.. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Азнакай районы Вахитов
авыл җирлеге башлыгы И.Б. Бохарова

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ВАХИТОВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ